| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге торак пунктлары территорияләрендә:

Апас районының Танай-Турай авылы;

Апас районының Урта Биябаш авылы;

Түбән Кама районының Ключ Труда поселогы;

Тукай районының Күперле авылы;

Тукай районының Кырныш авылы;

Теләче районының Тәмте авылы;

б) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Аксубай районының Такталы авылындагы Пушкин урамы;

Әлки районының Иске Салман авылындагы Үзәк урам;

Түбән Кама районының Ялантау авылындагы Нагорная урамы;

Саба районының Эзмә авылындагы Тынычлык урамы;

Саба районының Алан Елга поселогындагы Совет урамы;

Саба районының Иштуган тимер юл разъезды поселогында Күл буе урамы;

Саба районының Түбән Утар авылындагы Муса Җәлил урамы;

Саба районының Сабабаш авылындагы Кукмара урамы;

Теләче районының Теләче авылындагы Совет урамы.

2. Үз көчләрен югалткан дип таныйрга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы

булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 14 февралендәге ПУ-119 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 14 февралендәге ПУ-121 номерлы Указы.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 15 апрель
№ ПУ-382